БЕЗНЕҢ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 6 июленнән бирле чыга. | №112 (7885) | 19 сентябрь, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Сезон ябылды!

**18 сентябрьдә Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасының Каравыл Тавы кирпеч заводында кирпеч сугу сезонын ябу булды.**

Әйтергә кирәк, завод сезонны уңышлы тәмамлады. 1988 елдан бирле һәр елны кирпеч җитештерү 300 мең данәдән дә кимгә артмый. Былел исә 4900 мең данә кирпеч сугылды. Быелгы сезонда мастерлар О. И. Арбузов, Н. Е. Глухов, М. М. Тажиев, Н. М. Мандрейкин җитәкләгән сменалар даими рәвештә 3 сменалы эш тәэмин иттеләр. Иң күп кирпечне О. И. Арбузов сменасы җитештерде, ул 1550 мең данә исәпләнә. Н. М. Мандрейкин егетләре дә аннан азга калышалар, аларда ул 1480 мең данә сугылды. Формалау агрегаты һәм бишекле конвейерда эшләүче И. В. Майоров һәм Ю. С. Клементьев та һәр елны тик торуларга юл куймыйлар.

Эшчеләрнең җитештерүчән хезмәтендә производство начальнигы В. Х. Сәлаховның да өлеше бар дип әйтергә кирәк. Чөнки эшчеләрнең бер генә үтенечен дә игътибарсыз калдырмый ул, мөмкинлегеннән чыгып һәрчак аларны үтәргә тырыша.

Әнә шулай оештыру чараларын һәрьяклы уйлап, эшчеләр мәнфәгатен алгы планга куеп эш иткәнгә, уңышларыбыз да начар түгел. Җәйге сезонда безгә ярдәмгә килгән 2 нче мәктәп укучыларына, кирпечне борыслау һәм утыртуда булышлык күрсәткән шикәр заводы эшчеләренә дә рәхмәтебез зур. Бергә килешеп эшләүнең эшкә тәэсире аз булмады.

**Г. ПИМУРЗИНА,**
**комбинат экономисты.**

## ОПТИМАЛЬ СРОКЛАРДА

«Восход» колхозы. Биредә уҗым бодае һәм арыш чәчү, җирне туңга сөрү кебек көзге эшләр оптималь срокларда төгәлләнде.

Чәчүдә Т-4 тракторчысы Петр Капитонов эшне сыйфатлы итеп башкаруы һәм өлгерлеге белән башкалардан аерылып торды. Ул барлыгы 750 гектар мәйданда чәчү чәчте.

Туңга сөрүдә исә Т-4 тракторчысы Федор Ивановка тиңнәр булмады. Үз нормасын ул икеләтә арттырып үтәде. Ике дистә ел механизатор булып эшләү дәверендә Ф. Иванов үзен карусыз һәм тырыш кеше итеп танытты.

**А. АЛЕКСЕЕВ,**
экономист.

## Көннәр аяз торганда

«Знамя Октября» колхозы. Хуҗалыкта татлы тамырны җыю дәвам итә. Иван Ефремов һәм Фәнис Галимов җитәкчелегендәге бригадалар аеруча тырышлык куеп һәм вакыт белән исәпләшмичә эшлиләр.

Зур көч куеп үстерелгән чөгендерләрне югалтуларсыз җыеп алу өчен беренче бригададан РКС-6 чөгендер казыту комбайнчылары Владимир Мензелеев һәм Николай Тумаков аяз көннең һәр минутын отышлы файдаланып эшлиләр. БМ-6 яфрак урдыру комбайнына утырган Валерий Ефремов та шулай ук сынатмый.

Беренче бригада бүгенге көнгә 50 гектар мәйдандагы татлы тамырның 25 гектарын җыеп алды инде.

**Г. КУЛЬМЕТЬЕВА,**
экономист.



Бу рәсемдә сез «Кондырча» колхозы чөгендер игү осталары Рәисә Сафина һәм Хәнифә Әюпованы күрәсез.

Рәисә апа байтак еллар терлекчелектә эшләде, инде соңгы ун елда чөгендер игүчеләргә кушылды. Ә Хәнифә апа исә гомер буе татлы тамыр үстерүдә булды. Быел лаеклы ялга чыкса да ул басуны ташламады әле. Хәзер һәр ике уңган хатын-кыз быелгы уңышны җыючылар белән бергә басуда намуслы хезмәт куялар.

КИСКЕН СИГНАЛ

## Юкка көенмиләр...

**Хуҗалыкларда сөт җитештерү һәм сату белән мактанырлыгыбыз бер дә юк соңгы вакытта. Өстәвенә, шул шартларда да булганына бәрәкәт дип, анысын сыйфатлы килеш төгәл үлчәп озатсалар иде әле! Юк шул! Әледән-әле сөт-май комбинатына майлылыгы билгеләнмәгән, күләме күрсәтелмәгән продукция килеп тора. Әйтик, 17 сентябрь көнне заводка «Путь к коммунизму» колхозыннан 202 килограмм исәпкә алынмаган сөт китерелде. «Восход» колхозыннан килгән сөтнең 96, «Заря»ның 67, «Правда»ның 43 килограммы шулай ук исәпкә алынмаган иде. Менә шуннан аңла бу хуҗалык белгечләрен, юкка көенмиләр, барга сөенмиләр булып чыга түгелме соң бу?!**



**ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: «Рассвет» совхозы чөгендерчесе Гөлсем Әхмәдулловна Сатдарова.**

**Гөлсем Әхмәдулловна озак еллардан бирле татлы тамыр игүчеләр сафында хезмәт куя. Хәзер совхоз кырларында чөгендер казу ахырына якынлашып килә. Гөлсем һәм аның кебек хатын-кызлар аны үз вакытында чистартып дәүләткә тапшыру өчен көчләрен кызганмыйлар.**

## Районда чөгендер казу ничек бара?

**Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче—чөгендер чәчелгән мәйдан (гектарларда), өченче—аны җыюның үтәлеше (процентларда). Мәгълүматлар 1991 елның 18 сентябренә.**

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 150 | 47 |
| Ульянов исем. | 285 | 40 |
| «Правда» | 190 | 47 |
| «Восход» | 180 | 39 |
| Мичурин исем. | 240 | 71 |
| «Россия» | 215 | 46 |
| Хафизов исем. | 300 | 66 |
| «Путь к коммунизму» | 295 | 68 |
| Муса Җәлил исем. | 198 | 61 |
| «Родина» | 225 | 58 |
| «Игенче» | 300 | 43 |
| «Большевик» | 255 | 39 |
| «Заветы Ильича» | 150 | 73 |
| «Знамя Октября» | 100 | 70 |
| «Алга» | 195 | 73 |
| «Комбайн» | 180 | 79 |
| XXI партсъезд исем. | 190 | 63 |
| «Татарстан» | 135 | 56 |
| «40 лет Победы» | 200 | 30 |
| «Чишмә» | 255 | 39 |
| «Таң» | 150 | 43 |
| «Москва» | 245 | 47 |
| «Үрнәк» | 130 | 54 |
| «Лесная Поляна» | 40 | 75 |
| «Кондырча» | 160 | 50 |
| Кузнецов исем. | 235 | 21 |
| «Заря» | 215 | 40 |
| «Чирмешән» | 137 | 50 |
| «Ленинский путь» | 195 | 51 |
| «1 нче Май» | 155 | 29 |
| «Төрнәс» совхозы | 50 | 84 |
| «Мамык» совхозы | — | — |
| «Рассвет» совхозы | 370 | 76 |
| «Сөлчә» совхозы | 50 | 50 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 190 | 100 |
| Район буенча | 6560 | 56 |

## Ишеттегезме әле...

Санкт-Петербург мэры А. Собчак: «Әгәр кайдадыр ачлык башланса, аның сәбәпләрен экономикадан түгел, ә сәясәттән эзләргә кирәк. Грузия, мәсәлән, Россиядән, Казахстан яки Украинадан ашлык алмаса, ул ачлык кичерәчәк. Моңа юл куймау өчен экономик союз төзүне тизләтергә кирәк».

x x x

Элекке югары партия мәктәбен Себер гуманитар университеты итеп үзгәртергә— Новосибирскида җирле матбугат әнә шундый тәкъдим белән чыкты. Анда хокук белеме һәм дәүләт белеме учреждениеләре өчен белгечләр әзерләнәчәк.

x x x

Молдова Республикасы Президенты Указы белән бу республикада дәүләт иминлеге комитеты бетерелде. Аның урынына Милли иминлек министрлыгы оештырылды.

x x x

Бурятия авылларында аз тәэмин ителгән гаиләләргә укучы балалар өчен компенсация акчасы аена 70 сум түләнә.

x x x

Приморьеда Вострецово авыл Советы үз территориясендә икмәккә талон кертергә мәҗбүр булды. Иске пекарня көн саен 1600 ипи пешерсә дә, кешеләргә бу гына җитми —алар иртән иртүк чиратка чыгып басалар.

x x x

18 ел буе «патшалык итүе» чорында Брежнев хөкүмәттән 114 югары бүләк алган! Алар арасында 5 Советлар Союзы Герое һәм Социалистик Хезмәт Герое Алтын Йолдызы, «Победа» ордены, 16 орден һәм 18 медаль, бриллиантлы ике маршал йолдызы, почетлы корал һ.б. бар. Чит ил дәүләтләреннән 42 орден һәм 29 медаль алырга өлгергән. 1981 елда шәхсән аның өчен генә алтыннан «КПСС-та 50 ел» дигән билге эшләнгән. «Турылыклы ленинчы» үлгәннән соң аның дачасында «законлы» Алтын Йолдызлардан тыш өр-яңа тартмаларда тагын 34 Алтын Йолдыз табылды (13е—Социалистик Хезмәт Героеныкы, 21е—Советлар Союзы Героеныкы).

# БӨТЕН АВЫЛ БАСУДА

Комбайннан кагатка бушатылган чөгендерне чистартып торучы беренче төркем хатын-кызлар янына тукталдык. Зинаида Сергеева җитәкләгән звено чөгендерчеләре булып чыктылар. Зинаида Филипповна үзе авылдагы саклык кассасы мөдире, әмма колхозда кызу эш өстендә булышырга һәрчак әзер.

Җәен колхозчы хатын-кызлар белән беррәттән үзенә шикәр чөгендере игү өчен участок алган. Хәзер, билгеле инде, икенче урак өсте, үзе үстергән татлы тамырны җыеп тапшырасы. Төп хезмәтенә дә зыян килми, кассага акча салучы, алучы юк бу көннәрдә. Чөнки халык басуда.

Һәм бу чынлап шулай. Аның ише хезмәткәрләр генә түгел, пенсионерлар да чөгендер чистарта. Әлеге звенода гына да колхозчылар Полина Имукова, Зинаида Портнова белән пенсионерка Зинаида Магина, Мария Терентьева да кулларында ут уйнатып эшлиләр. Соңгысына аерым тукталу да урынлы, 63 яшенә җитсә дә яшьләрдән һич калышмый: чөгендерне җәһәт-җәһәт чистарта һәм кагатка ташлый бара.

Андыйлар янәшә участокта да бар. Тамара Яллина һәм Надежда Перепелкина мәктәптә эшлиләр, бер үк вакытта басуда да хезмәт куялар. Елена Имукова ашханә мөдире, әлегә декрет ялында, әмма бүген ул да басуда. Шул ук төркемдә чөгендер чистартучы Любовь Михеева склад мөдире, үз урынына пенсионер әтисен калдырып килгән.

Идарә аппараты, авыл интеллигенциясе работниклары да үзләреннән шәхси өлеш кертәләр. Азык чөгендере кырында өлкән класс укучыларының 30 кешедән торган производство бригадасы хезмәт куя. Алар да өлкәннәрдән ким тырышлык куймыйлар. Үзләре сирәкләгән кырдагы мал азыгын чистартып, өемнәргә салып баралар. Аны хуҗалыкка үзләре үк тапшырачаклар да. Бу элекке еллардан үк шулай килә. Хезмәтләренең нәтиҗәсе дә сөенерлек, кем әйтмешли, чөгендерләре самовар-самовар. Яз корылыклы килсә дә, уңышны мул үстергәннәр, һәр гектардан 400 центнер азык чөгендере көтелә. Бу алдагы елдагыдан күбрәк.

—Кышлату чорында фермада ит, сөт җитештерү әйбәт дәвам итсен өчен азык чөгендере туклыклы азык,—ди колхоз рәисе Юрий Владимирович Терентьев.—Һәм без моның өчен беренче чиратта мәктәп укучыларына бурычлы. Аларга олы рәхмәт.

Колхозчы хатын-кызлар өчен дә бүген төп эш — шикәр чөгендере уңышын җыю. Алар күнегелгән хезмәттә сынатмыйлар, көннәр аяз торганда чималны чистартып, озатып калу өчен тырышалар.

«Россия» колхозында шикәр һәм азык чөгендере 250 гектарга якын мәйдан били. Аның уңышын җыюда механизаторларның да фидакарь көч куюын билгеләп үтү кирәк.

Хуҗалыкта сөрүлек бар җирләр ике аренда звеносына беркетелгән. Чөгендер басулары да шул звенолар карамагында. Ә соңгысының уңышын җыюда 4 комплекс эшли.

Беренче звенода татлы тамыр казу Николай Перепелкин һәм Геннадий Трофимовка йөкләтелгән. Хезмәт сөючән механизаторлар алар, вакыт белән һич санашмый эшлиләр. Комбайннары төзек, ритмлы эшли. Туфракта дым мул булганга беренче тизлектә генә эшлиләр, сыйфатка зыян китермиләр.

Икенче звенодагы чөгендер комбайннарын да хезмәткә сынау узган осталар җитәкли. Владимир Магдрейкин РКС-6 белән казыта чималны. Күз тимәсен, ихлас күңелдән башкара вазифасын.

Анатолий Терентьевның КС-6 сы 1985 елдан бирле басуда уңыш җыюда катнаша. Комбайны искергән, башка кеше кулы аша узып өлгергән булса да, соңгы елларда ягъни аңа килеп эләккәч, ышанычлы эшли кырда. Былтыр, мәсәлән, 70 гектарга якын мәйданнан чөгендерне чыгарган. Хәер, быел да сынатмый тәҗрибәле оста. Чөгендер казуга берничә көн элек кенә төшкән булсалар да, рекордлар куеп өлгергән инде. Мисал өчен бер көнне нормадагы 5,2 гектар урынына 8 гектар җирдән татлы тамыр алган. Башка көннәрдә дә смена заданиесен күпкә үтеп китә.

Чистартылган чимал да басуда озак ятмый. Үзбушаткыч автомобильләр шоферлары Василий Кадяшев, Анатолий Михеев, Сергей Еграшкин көн саен заводка 5—7 рейс ясап өлгерәләр. Алар өчен кагат кырында әлегә чират юк, шуңа тиз әйләнәләр. Николай Михеев исә бер көндә 8 йөк чимал илтеп өлгергән. Басуда да тоткарлык юк, ике төягеч машина әрҗәләрен берничә минут эчендә тутырырга җитешә.

Без басуда булганда, ягъни 12 сентябрьдә хуҗалык уңганнары әнә шулай өлгер эшли калдылар. Чимал чыгаруга колхоз шоферларыннан тыш Чистайдан өстәмә автомобильләр дә килде. Ул көнгә татлы тамырның өчтән беренә якыны казылган иде инде.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**
«Россия» колхозы.



**Николай Алексеев—«Октябрьскагропромхимия» район берләшмәсендә уңган механизаторларның берсе. Ул КамАЗ автомобилен идарә итә. Ул эшләгән техника район хуҗалыкларына әче туфракларны эшкәртү өчен известь ташуда катнаша. Булсынга дип эшли Николай, автомобиленә прицип тагып төйи йөкне. Үзе дә тырыш, билгеле, ай саен җиткерелгән заданиене арттырып үтәп килә. Үткән 8 айда да ул бу төр йөк ташучы шоферлар арасында алдынгы урыннарның берсен яулады.**

**Рәсемдә: «Октябрьск-агропромхимия» шоферы Николай Алексеев рейска чыгар алдыннан.**

■ **Газетага язылу көндәлеге**

## ҺӘР ЕЛНЫ АЛДЫРАМ

Мин район газетасын һәр елны алдырып, кызыксынып укып барам. Һәм район тормышының киң яктыртылуы, яңалыкларның оператив бирелеп баруы ул үз вазифасын лаеклы үти дигән фикер тудыра күңелдә. Газетаның район хуҗалыкларының игенчелектә, терлекчелектә ирешкән күрсәткечләренең оператив сводкасын әледән-әле биреп баруы да бик әйбәт. Һәм шулай ук авыл хуҗалыгының төрле тармагы буенча белгеч киңәшләре дә һәр хуҗалыкта эшне оештыруда яхшы кулланма.

Гомумән, газетабыз район халкына хезмәт күрсәтү буенча инде 60 ел хезмәт итә. Шулай булуга карамастан, яшьләргә хас ялкынлылык белән җәмгыятебез алдында торган социаль, экономик бурычларны хәл итүгә булышуда сәләтен дә, көчен дә кызганмас дип ышанам,

**В. САШИН,**
Чуваш Тимерлеге авыл Советы рәисе.

## Беренчеләрдән булып

**«Комбайн» колхозы.** Хуҗалыкның Яңа Әмзә бригадасы колхозда беренче булып чөгендер казуны төгәлләде.

106 гектарлы мәйданда ике механикалаштырылган звено иртәнге 5 тән кичке 9 га кадәр өзеклексез хезмәт куйды. Беренче звенода КС-6 чөгендер алу комбайнында Ясәви Әхмәдиев, БМ-6 белән яфрак урдыруда Рөстәм Сәмәрханов, икенче звенода шул ук хезмәтләрне башкаручы Тәлгать Мәсгутов, Ринас Мотаһиров бернинди вакытлы тукталуларга юл куймадылар. Алар артыннан чөгендерне кагатларга ГАЗ-53 машинасы белән Нәкыйф Мәхмүтов, ЗИЛ-130 белән Әкрәм Минапов, ЗИЛ-130да Фоат Нәбиуллин һәм ГАЗ-53 тә Гали Нәбиуллин ташып тордылар.

Чөгендер яфрагын силослау өчен ташуда эшләүче Хөҗҗәт Зәйниев, Вәкил Гатин, Абдулла Гайсин һәм Айрат Локманов хезмәтенә дә мактаудан кала сүз әйтерлек түгел иде.

Кырда эшләүчеләр өчен шартлар тудыру да чөгендерчеләрнең кәефенә әйбәт йогынты ясады. Механизаторлар өчен кайнар аш оештырылды, чөгендерче апайлар теләге буенча аларга да кайнар ризыклар ташыла, кырда икмәк сатыла. Иртәнге 7 дән кичке 7 гә кадәр басуда булган апайлар да тизрәк чөгендерне чистартып, озатып бетерү теләге белән яналар. Хәзер хуҗалыкның беренче бригадасында Әүхәт Галимовның аренда звеносында да эш төгәлләнү алдында тора.

**Р. НАСЫЙБУЛЛИН.**

## «Салават күпере»нә—5ле!

**Нәниләр өчен чыга торган «Салават күпере» журналы 3 нче санында әти-әниләргә үзе турында берничә сорау биргән иде. Рәхмәтләр һәм мактаулар тулы бик күп хат алды ул. Әниләр һәм әтиләр генә түгел, әбиләр һәм бабайлар, кызлар һәм малайлар, укытучылар, тәрбиячеләр—һәммәсе!—журналны бик яратуларын әйтеп, бизәлеше өчен «зур», «таза», «нык», «алты янында торган» «5»ле куярга тәкъдим иткәннәр!**

**«Салават күпере» киләсе елда да «5» ле куярлык итеп чыгарга җыена. Кәгазе һәм буяулары элеккечә затлы булачак. Журнал хәзергә Татарстанда гына таралачак.**

**Индексы—73953.**

**Ярты елга язылу бәясе—9 сум, бер елга—18 сум.**

## Колбай Морасада—мәчет

Гаиләм белән Морасага ялга кайтуымның беренче көннәрендә үк мәчеткә бармый кала алмадым. Чөнки бу мәчетнең салынуына минем дә бабай-әтиләремнең өлеше зур булган. Кешеләрнең һәм әнинең сөйләвеннән күренгәнчә, минем әти-әни ягыннан ике бабам да байлар булганнар. 1916 елда Морасаның дүртенче мәчете төзелешенә зур акчаларын, хезмәтләрен керткәннәр. Бу мәһабәт зур мәчет бинасы кызыл таштан төзелгән (элек Морасада 4 мәчет булган. Шуларның өчесе шул чордагы авыл куштаннары, активы тарафыннан тулысынча юк ителгәннәр). Манарасын төзеп бетерә алмаганнар.

Шуннан соңгы чорда милләтебез генә түгел, динебез дә Сталин—Хрущев—Брежнев иттарткычына салынып юкка чыгарылуга дучар ителде. 75 ел буена кадерле тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне, телебезне, белемле-укымышлы кешеләребезне югалта килдек. Хәзер заманалар үзгәрә башлады. Менә 1990 елның ноябрь аенда авылның абруйлы-динле кешеләренә исән калган бер мәчетнең бинасы кайтарып бирелде. Мәчетне халыкка кире кайтарып алуда Минсәлим Сафин, Гасыйм Хөснетдинов, Харис Садретдинов һәм башкалар башлап йөрделәр. Тырышлык, күргәнебезчә, бушка китмәде. Хәзер Мораса мәчетендә һәр җомга сәгать 12 дә намаз уку бара.

Мәчетне ремонтлауда, төзекләндерү, буяу-агарту эшләрендә хәләл җефете белән бергә Абдулла Ярулла улы Садыйков зур хезмәт алып баралар. Материал, транспорт табу да алар кулы, тире белән эшләнә. Бу иптәшләргә авыл хезмәтчелләренең рәхмәте бик зур. Хәзергә әле мәчеткә 15 ләп кенә кеше килә. Ярдәм итүчеләр дә аз. Бигрәк тә авыл Советы һәм колхоз идарәсеннән ярдәм кирәк. Башка авыл-шәһәрләрдә колхоз, авыл, шәһәр Советы җитәкчеләре башлап йөрсә яки акчалата ярдәм итсә, Морасада әле аларның юмартлык күрсәткәннәре юк икән. Мәчеткә ремонт ясауда төзелеш материаллары белән ярдәм итәсе иде. Агач материаллары, мәчетнең 1916 елда төзелеп бетмәгән манарасын кору өчен кирпеч кирәк. Мәчет урта мәктәп бинасыннан 20—30 метр ераклыкта гына урнашкан. Аларның үзара ярдәмләшеп, дус-тату яшәүләре бик мөһим. Киләчәктә бәлки авыл урта мәктәбендә дини дәресләр кертергә яки курслар ачарга мөмкинлек булыр. Хәзер бит татар теленә күчереп бастырылган Коръән сүрәләре, догалар, ислам дине йолалары язылган китаплар бик күп. Аларны да яшьләргә аңлату артык булмас. Ни дисәң дә ислам диненең телебезне, милләтебезне саклап калуда, халкыбызда әдәп-тәртип, сафлык тәрбияләүдә башлап йөрүен онытмыйк.

Хәзергә, әйткәнемчә, мәчет ярдәмгә мохтаҗ әле. Әйдәгез, милләттәшләр, ата-бабаларыбыз мирасын—мәчетне саклап калуда ярдәм итик. Бу максатларда акча күчерергә теләүчеләр өчен адрес: Колбай Мораса авылы, Абдулла Ярулла улы Садыйковка. Тарихын, милләтен яраткан һәр кеше бу эштән читтә калмас дип ышанам.

**Р. ВӘЛИЕВ,**
Ленинград мәдәният үзәге советы әгъзасы.

# Синдряковлылар көзге чорда

**—Синдряков исемендәге колхоз башка колхозлардан кайсы ягы белән аерылып тора?**

**—Советлар Союзы Герое Н. К. Синдряков исемен йөртүе белән.**

**Колхоз рәисе Сергей Ильич Белогубов белән очрашуыбыз нәкъ шулай башланды. Ул илтифат белән үзе җитәкләгән хуҗалыкны күрсәтеп чыкты, колхозчылар, кырда эшләүчеләр белән таныштырды.**

Үз героен халык чынлап та онытмый биредә. Бигрәк тә мәктәп балаларда кече яшьтән үк аңа хөрмәт хисе тәрбияләп килә. Ел саен Н. К. Синдряковның туган һәм һәлак булган көннәре билгеләп үтелә, махсус кичәләр үткәрәләр. Ә бер елны Украинага барып, ул көрәшкән урыннарны, аның каберен күреп кайттылар. Ә колхозда волейбол, чаңгы ярышлары аның призы исеменә үткәрелә. Герой исемен йөртүче колхоз авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү буенча элекке елларда районда иң алдынгы, әйдәп баручы колхозларның берсе иде. Ләкин тормыш бертөрле генә акмый. Бу хуҗалык хәзер урталыкта көн күрә бирә. «Хикмәт урындамыни соң?—ди колхоз рәисе.—Безнең өчен алда булу максат түгел. Иң мөһиме, авыл халкы туйганчы ашасын, аларның социаль көнкүреше яхшырсын. Аннары мактанчыклык безнең буынның бәласы, дим мин». С. И. Белогубов колхозны әле ел ярым тына җитәкли. Күрәсең, принциплары да элеккечә «кушканны эшлә» түгел,«ә үзенчә уйлап, үлчәп эшлә»гә кайтып кала—колхозчылар белән дә мөнәсәбәтләрне ул нәкъ шул принципта төзи.

Электән үк Иске Чаллы авылына читтән килеп торучылар күп булган. Әлбәттә, аларга яшәү өчен йорт та кирәк. Быел да индивидуаль йорт салучылар байтак биредә. Башлаган эшләрен уңышлы башкарып чыксын өчен колхоз да аларга булышлык күрсәтә.

Әле менә авыл эчендә юл да күтәрелә. Хәзерге вакытта җитәкчелек өйләргә газ кертүгә хәзерлек эшләре белән янып йөри.

## Яхшы азык хәзерләнә

Узган елда хуҗалыкта байтак җирләр сөрелмичә кала, кырлардан салам да чыгарылып бетми. Билгеле ки, язгы эшләр озакка сузыла, шунлыктан чәчеләсе культуралар соңрак чәчелә, быелгы корылык та өстәмә бәла булып килә. Нәтиҗәсе таныш: уңыш та бик аз алына.

—Колхозчыларны туйганчы ашата алсак кына, фуражга иген калмас быел,—ди колхоз рәисе терлекләрнең кышлыгын кайгыртып. Бәлки бу да этәреш булгандыр, колхоз быел терлек азыгын мул һәм сыйфатлы итеп әзерләүгә зур көч куйды.

Саламны гына алыйк.

—Былтыр салам эскертләренә карарга оят иде,—ди Сергей Ильич, биек салам өемнәренә күрсәтеп,—быел ел ярымга җитәрлек хәзерләдек.

Бу мәсьәләдә колхоз җитәкчелеге тарафыннан эшне оештыруда бер төрле кызыксынучанлык күрсәтелә. Шунлыктан эшнең иң кызу вакытында, эшче куллар санаулы чакта салам өюгә пенсионерлар да тартылалар. Алар—Дмитрий Алексеевич Кузнецов, Петр Афанасьевич Артемьев. Ә Сергей Евгеньевич Фомин трактор белән өеп торды. Печән җыю һәм хәзерләү буенча да шул кешеләр тырыш хезмәт күрсәтте.

Хуҗалыкта 150 гектар җирдә кукуруз чәчелә. Ул быел яңа сортлы. Биредә район хуҗалыкларындагы белән чагыштырмача иң яхшы кукуруз үскән дияргә була. Шуңа да колхозчылар аны зур күтәренкелек белән җыялар. Ике адаш Владимир Красников һәм Владимир Захаров, уручылар Т-150 тракторлары белән Анатолий Захаров, КамАЗ машинасында Петр Тугасев кукурузга төшкәннең беренче көненнән үк ташып торучылар булалар. Силосны 1700 тонна азык сыешлы базга китерәләр. Быел анда биш компоненттан торган азык катнашмасы салына. Шул исәптән рапста кушалар.

—Кукурузның әчелеге бетсен өчен, махсус рәвештә соңрак урырга керештек,—ди Сергей Ильич,—ә протеинга бай рапс белән бергә алар яхшы азык булырга тиеш.

Бу җаваплы эш Валерий Егорович Попов, Сергей Валентинович Захаров, Виктор Яковлевич Ниловка һәм Сергей Евгеньевич Фоминга тапшырылган. Алар кышкылыкка дигән сусыл азыкны бөтен нормаларны күздә тотып базга салып тордылар.

## Киләсе ел уңышына

Колхоз 1800 гектар җирне туңга сөреп калдыра. Үткән елның сабагы кыйммәткә төшә; быел барысы да үз вакытында эшләнә. Хәер, табигать шартлары да моңа комачаулык итмәде бит. Сөрүчеләр Александр Иванович Никифоров, Борис Дмитриевич Шувалов һәм әле генә мәктәпне тәмамлап кырга килүчеләр Геннадий Бойков, Александр Екамасов. Алар тырышлыты нәтиҗәсендә киләсе ел уңышына нигез салына.

750 гектар җирдә уҗым культуралары чәчелә. Тик колхоз рәисе бу мәсьәләдә бер борчуы белән бүлешмичә булдыра алмады: «Матур гына чыгып килгән уҗым культураларын шәхси хуҗалыклар терлегеннән саклап бетерүе мөмкин түгел»,—ди ул. Шунысы күзгә ташлана, моңардан чыгу юлын да тапканнар, терлек керү куркынычы булган җирләрдә траншея казып чыкканнар. Гомумән, чәчүлекләрне саклауга зур көч куела биредә.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

## Бүгеннән әзер

**«Заря» колхозы.** Хуҗалык быел терлекчелек фермаларын ремонтлауга бик күп көч куйды. Маллар лагерьда булганда, 4 рәтле сыерлар абзарында тулысы белән реконструкция үткәрелде. Иң элек аның түбәсе, ишекләре алыштырылды. Бу эш белән авылның өлкән яшьтәге картлары шөгыльләнде. Василий Яковлевич Ухваньков, Василий Яхунович Сандимиров, Исай Хәйруллович Мөхетдинов агач-ремонт эшләрен җиренә җиткереп үтәделәр.

Ферма эчендәге сууткәргеч, сөт саву вакуум линиясен исә «Агропроммехмонтаж» ПМКсы алыштырды. Шул ук ферманың азык салу тагараклары, идәннәре дә бетонланды. Бинадан чыгарылган тиресне туплау мәйданчыгына плитәләр җәелә хәзер. Бинаның эче-тышы агартылды, чистартылды. Маллар тотыла торган кардалар яңартылды.

Ферма тирәсендәге юллар да элек-электән халыкның теңкәсенә тигән иде. Быел бу юллар күтәрелде, хәзер бирегә вак таш ташыйлар. Сүз уңаеннан, терлекчелеккә караш үзгәрүен яздан ук тойганнар иде инде биредә. Ник дигәндә, быел бер дигән җәйге лагерь булдырылды, анда универсаль сөтүткәргеч сузылды. Савучылар җәйге чорда аның бик җайлы булуын әйтеп торалар. Хәзер зарялыларның бозаулату бүлеге бинага кайтты инде. Акмурзиннарның гаилә подряды белән эшләүче коллективы да фермада. Озакламый 4 рәтле сыерлар абзарына да маллар кайтуын көтәләр. Ә ул бүгеннән әзер.

## Барысы да беренче класслы

Киләсе ел уңышы өчен орлык әзерләүгә быел бик җитди карадылар «Заря» колхозында. Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки яхшы уңыш нигезе—яхшы орлык ул. Шуңа урак барышында ук орлыклык материал әзерләүне икенче планга куймадылар. Иң элек аны ОВП-20 аша үткәреп, беренчел чистарту үткәрделәр. Бу эшне Валерий Артюшкин һәм Валерий Иванов башкардылар. Аннан инде орлыклык материал ЗАВ-20, ЗАР-5 аша икенче кат чистарту үтте. Бу эш тә җиренә җиткереп башкарылды, чөнки чистарткычлар машинистлары Александр Романов һәм Валерий Молодцов әлеге хезмәтне күптәннән һәм бик белеп башкаралар. Гомумән, орлык әзерләргә тартылган һәркем әйбәт хезмәт куйды. Аны амбарларга ташып, урнаштырып торучы ГАЗ-53 машинасы шоферы Владимир Яковлевич Савельев, Анатолий Казаков, Александр Евдокимов та, үлчәүче Людмила Перепелкина да өлгер, төгәл булдылар. Пенсионер Анисим Александрович Максюткин да орлык әзерләүчеләргә нык булышлык күрсәтте. Ә орлыкның сыйфаты, дымлылыгы колхозның агрономия служебасының ныклы күзәтүе астында булды, ул җиренә җиткереп үтәлде. Инде орлык саклансы бинаны әзерләүгә килгәндә, склад мөдире Анатолий Степанов шулай ук бик төгәл, җыйнак кеше. Ул апайларның бердәм эшен оештыра алды. Биналарны чистарту, аклау -дезинфекцияләүдә Ирина Питубаева, Ольга Алякимова, Валентина Акмурзина, Елена Фролова күп көч куйдылар.

Колхозның орлыклык фонды әнә шулай гомуми тырышлык белән тупланды. Нәтиҗә бик куанычлы: ул тулысынча беренче класс таләпләренә җавап бирә.

**В. ИШТУЛЛИН.**



**Колхозда алар икесе дә байтак еллар хезмәт куялар. Берсе— Габделхак Вәлимөхәммәтович Бадыгин ындыр табагында машинист, ашлык чистарту машиналарының көйле эшләвен тәэмин итүче булып эшләсә, икенчесе—Габделхак Бикмөхәммәтович Вәлиәхмәтов—хуҗалыкның машина-трактор паркында мастерской мөдире.**

**Икесе дә колхозда абруйлы кешеләр. Нинди генә эшкә алынмасыннар, аны җиренә җиткереп, намус белән үтиләр. Шундый тыйнак, тырыш иптәшләренә карата гадел булганы өчен дә хөрмәт итәләр үзләрен.**

**Рәсемдә: Муса Җәлил исемендәге колхозның ындыр табагы машинисты Г. В. Бадыгинны һәм мастерской мөдире Г. Б. Вәлимөхәммәтовны күрәсез.**

## Эш көйле бара

**«Ленинский путь» колхозы.** Хуҗалыкта хәзерге вакытта бөтен көч 195 гектар мәйданда үстерелгән татлы тамырны җыеп алуга бирелгән. Көннәр тотрыксыз булуга карамастан, эш темпын киметмәскә тырышабыз. Хәзер кырда БМ-6 яфрак урдыргыч комбайннарында эшләүче Павел Борков, Петр Иванов, Виталий Волковлар да һәм шулай ук РКС-6 чөгендер казыту комбайннарында эшләүче Алексей Исаев, Николай Ермуллин, Владимир Фролов та эштә сыната торганнардан түгел.

Чөгендер алуның хәзер күбрәген техника башкарса да, колхозда чистарткычлар булмау сәбәпле кул хезмәте дә кулланыла әле. Валентина Тимофеева, Вера Михайлова, Валентина Зайцева, Зинаида Фатькина җитәкләгән звено хатын-кызлары да, идарә хезмәткәрләре, авыл интеллигенциясе һәм мәктәп балалары да үстерелгән чөгендерне кырдан шикәр заводына тизрәк озатуны максат итеп, тырышып эшлиләр. Безгә шулай ук халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты да зур ярдәм күрсәтә. Алар 30 гектар мәйданда җәен чүп утау, сирәкләү эшләре башкарсалар, хәзер җыеп алуда да бик теләп булышалар.

Чистартылган чөгендерне төяп торуда Анатолий Тимофеев, Алексей Чернов эштә өзеклек тудырмыйча эшлиләр.

Кыр-завод конвейерының соңгы звеносы булган, чималны ташуда безгә Бөгелмә УТТсыннан ярдәмгә килгән Р. И. Шәйдуллин, В. Б. Курлянов, Норлат агропромхимия берләшмәсеннән М. С. Гатин, Норлат тармакара производство предприятиесеннән А. Кәримов зур тырышлык куеп эшлиләр. Бүгенге көнгә барлык мәйданның яртысыннан күбрәгендә чөгендер җыеп алынды.

**Н. СИДОРОВА,**
колхоз рәисенең экономика буенча урынбасары.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Быелның 1 июленнән башлап, Чаллы шәһәрендә санитария-экология милициясе эшли башлады.

Хәзер торак йортлар тирәсендә чүп-чар яндыручылар—500, агач сындыручылар—300, куаклыкларга зыян китерүчеләр—200, торак йортларның ишегалларын һәм баскычларын чүпләүчеләр—100, кичке сәгать 10 нан иртәнге сәгать 6 га кадәр ишегалдында транспорт калдыручылар 40 сум штрафка тартылачаклар.

*Футбол күзәту*

# ТАМАШАЧЫ КАНӘГАТЬ КАЛДЫ

«Факел»ның Ковылкинода «Спартак» белән уйнавы турында алдагы күзәтүдә үк язылды, ләкин нәтиҗәләре билгесез иде. 6 сентябрьдә узган бу очрашу хакында «Факел»ның начальнигы Александр Хардин түбәндәге аңлатманы бирде.

«Безнең стадионда очрашу барышында «Спартак»ны 2:0 исәбенә отып җибәргән идек. Чит кырда уйнаганда да якташларыбыз өстенрәк иде. Ләкин шулай килеп чыкты ки, бу юлы бер генә очко ала алдык. Вячеслав Тураев һәм Ринат Минһаҗетдинов берәр туп керттеләр. Ә тагын бер тупны судья санамады.

Шуны да әйтик, «Спартак» уенчылары безнең кырда кагыйдәләрне еш боздылар. Бу юлы да ул гадәтләрен ташламаганлыкларын күрсәттеләр. Шулай да инициатива безнең кулда булды. Исәп безнең файдага 2:1 чагында икенче тайм тәмамлануга 11 минут кала безнең капкага пенальти билгеләнде. Көндәшләребезне җиңелүдән шул коткарды.

Бер уңайдан читтә үткәрелгән тагын бер уеныбыз хакында да әйтеп узу кирәк. Икенче очрашуыбыз Саранскның МГУ командасы белән булды. Уен тигез барды. 41 минутта безнең капкага пенальти билгеләнде. Бу очрашуның язмышын шул туп хәл итте».

Шулай итеп Идел буе зонасында РСФСР беренчелегенә ярышларда норлатлылар ике уенда бер очко туплау белән чикләнделәр.

11 сентябрь көнне тамашачылар шәһәр стадионында Әлмәтнең «Электрон» командасы белән очрашуны көткәннәр иде. Кунаклар аңа килмәде, уенсыз гына җиңелү белән ризалаштылар. 13 сентябрьгә билгеләнгән Пенза өлкәсенең «Дорожнигы» белән очрашу да булмады, элеге команда ярышлардан төшеп калган булып чыкты. Болар тамашачы өчен күңелле хәл түгел, әлбәттә, алар уен, футбол кырында кискен көрәшне көтә.

Хәер, Чабаксарның«Энергия» командасы белән 15 сентябрьдәге очрашу әнә шулай киеренке башланып китте дә. «Факел» беренче минутлардан ук һөҗүмгә ташланды. Уен башыннан ук кунакларга гел куркыныч янады. Нәтиҗәсе дә озак көттермәде. Ун минут артык узуга көндәшләр капкасына 20 метрлар читтән штраф тибү билгеләнде. Аны тибүче Газинур Хәмидуллин бөтенесен төгәл исәпкә алган булып чыкты: туп көндәшләр стенкасы өстеннән узып капканың өске почмагына килеп керде. Капкачы бу очракта көчсез иде.

Тагын өч минут та узып өлгермәде «Энергия» капкасына икенче туп керде. Бу юлы тамашачы күңеленә хуп килгән комбинацияне Ирек Исламголов матур итеп төгәлләде.

Көндәшләребез бу хәлне күреп капкачыларын алмаштырдылар. Һәм бу дөрес булды дияргә кирәк, югыйсә исәп тагын шактый арткан булыр иде. Яңа капкачы кунакларны берничә тапкыр кыен хәлдән коткарды.

Ләкин бөтен очракта да түгел. 30 нчы минутта көндәшләр капкасы төбендә куркыныч хәл килеп туды. Капка төбендә торган Вячеслав Тураев баш белән тупны капкага юнәлдерде. Капкачы аны тота алмады, сугып җибәрде. Туп якында торган Валерий Шарин янына төште. Ул аны капкага юнәлдерде.

Позицион өстенлек икенче таймда да безнең якта иде. Ләкин норлатлылар җиңү тәэмин ителгән санап тынычлана, киеренкелекне йомшарта төштеләр. Моны сизеп, кунаклар аратирә һөҗүм оештыра алдылар. Һәм почмактан тибүдән соң безнең капкага бер җавап тубы керттеләр. Шулай уен безнең файдага 3:1 исәбе белән төгәлләнде.

23 сентябрьдә «Факел» үз кырында Зеленодольск «Прогресс»ын кабул итә. Очрашу 16 сәгатьтә башлана.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**



## Фоторепортаж





## ҖӘЙНЕҢ БЕР КӨНЕ

Күңел тәрәзәләрең киң булса, табигать кочагына чык, вакытыңны бушка уздырма. Югыйсә, күп нәрсәне югалтасың. Без менә гаиләбез белән ял итәбез. Әлбәттә инде, кулга фотоаппаратны да алдык. Шундый сихри матурлыкны, җәйнең бер көнен истәлеккә төшереп калдырасыбыз килде.

Чыннан да, онытылмаслык бит җәйнең бу кояшлы, җылы көннәре: төнбоеклы күл буенда рәхәтләнеп су коену, кояшта кызыну һәм туйганчы яшел бишек кочагында тирбәлә-тирбәлә таган атыну...

С. Майстер фотолары.

### СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ? САЛЬМОНЕЛЛЕЗ

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, гәрчә бу авырудан үлүчеләр күп булмаса да (бер миллион кешегә берәү генә туры килә), сальмонеллез куркыныч авыру дип санала. Бигрәк тә балалар, картлар, йөкле хатыннар, шулай ук наркотик кулланучы һәм СПИД белән авыручы кешеләр өчен куркыныч ул.

Туклану продуктлары, бигрәк тә ит продуктлары сальмонелла белән теләсә нинди стадиядә—аларны җитештерүдән алып куллану өчен әзерләүгә һәм саклауга кадәр—йогышлана ала.

Испаниянең санитария хезмәте экспертлары раслаганча, тавыкларны ачык вольерларда түгел, ә ябык биналарда үстерү куркынычсызрак.

Тавык сую урыннарында да сальмонелла белән йогышлану куркынычы бар. Шунлыктан ит эшкәртү предприятиеләрендә камилрәк җиһазлар куярга һәм суюда яңа технологияләр кулланырга тәкъдим ителә.

Ә хәзергә, сальмонеллез белән йогышлану чыганаклары тулысынча бетерелмәгәнлектән, белгечләр продуктларны әзерләү һәм саклау вакытында гигиенаны нык сакларга кушалар. Сальмонелла бациллясы Цельсий буенча 70 градустан югарырак температурада гына һәлак була.

## Телевидение

**ЯКШӘМБЕ**
**22 СЕНТЯБРЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

16.10 Мультфильм.
16.20 Реклама.
16.25 «Киң Иделдә». Киножурнал.
16.45 Р. Бохараев. «Каюм Насыйри урамы». Телеспектакль. 1 нче һәм 2 нче серияләр.
19.30 «Әлли-бәлли-бәү».
19.40 «Җырлы туган як».

**I ПРОГРАММА**

8.00 Формула С.
8.30 ТЯХ.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 Иртән иртүк.
10.00 Ватанга хезмәттә.
11.00 «Таң йолдызы».
12.00 Сәяхәтчеләр клубы.
13.00 Авыл сәгате.
14.00 «Пи» билгесе астында. 1 бүлек.
15.00 ТЯХ.
15.15 «Пи» билгесе астында. 2 бүлек.
15.45 Яңа буын сайлый. «Экологик бумеранг».
17.00 Халыкара панорама.
17.45 Авазлар күп—дөнья бер.
17.50 Концерт.
18.05 Уолт Дисней күрсәтә.
18.55 «Брэйн Ринг». Яшьүсмерләр турниры. Одесса һәм Муром командалары очраша.
19.30 «Сериалдан качу». Нәфис фильм.
21.00 Информацион программа.
21.40 Футбол күзәтү.
22.10 «Алтын тире».
23.40 ТЯХ.

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Күнегүгә бас!»
8.30 «Тауларда йөрергә».
9.00 Концерт.
9.50 Док. фильм.
10.00 Балалар һәм ата-аналар өчен.
11.00 «Изге һәм мәңгелек».
11.15 «Билгесез Россия».
12.15 Фил Донахью программасы.
13.05 «Бу борынгы, борынгы тасмалар». К. Шульженко.
13.35 «Коткар һәм сакла».
14.20 «Ул яраткан хатын». Нәфис фильм (АКШ).
20.30 Сәяси программа.
22.40 «Җанрны эзләгәндә». Л. Филатов.
23.00 Хәбәрләр.

**Мөхәррир урынбасары Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.**

**Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 112. Тираж 3413.**